КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 декабрь г.Казань № 1236

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 декабрь, 1041 нче карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 декабрь, 1041 нче карары белән расланган Яңа инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын каплау өчен юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктта:

беренче абзацта «5 эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «30 нчы» сүзләрен «43 нче» сүзләренә алмаштырырга;

2.10 пунктта «заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән 10 календарь көн эчендә» сүзләрен «заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән өч эш көненнән артмаган срокта» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Министрлык сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) билгели һәм заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән өч эш көненнән артмаган срокта субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә һәм 2021 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була;

бу карарның гамәле 2021 елның 8 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин